

Торбеево районы авыллары элек-электән vзенен зур унышларга ирешкән халкы белән данлыклы. Һади Такташыбызча әйткәндә: «Белмим, Әллә кvпкә, Әллә бик озакка, Ахры, мәнге оныта алмамын Тамбов урманнары уртасында Усак яфраклары шаулавын... » Әлеге сvзләр авторнын Сыркыдысы турында гына тvгел, ә һәрбер кешенен туган ягы турында. Сvзебез туган ягыннан еракта гомер итеп тагы туган туфрагына кайтып гомер иткән Зәкия Мәхмvт кызы Утешева турында.

Такташыбызнын Сыркыдысынын кvршесе - Татар Юнки авылы. Зур тvгел ул авыл, әмма бvген Шамиль Тарпищевы белән Россиянен торле почмакларында янгырый. Гади авыл халкы да тырыш хезмәте белән билгеле. Торбеево районы Татар Юнки авылында туып vскән Зәкия Мәхмvт кызы Утешева да.

Тормыш бик кызыклы, матур, авыр нәрсә ул. Мидхать Исмаил улы белән Сәидә Хәсән кызы Утешевлар гаиләләрендә оч кыз тәрбияләнгән, ә Зәкияләре – ин олылары. Сәидә Хәсән кызы гомеренен кvп олешен армый-талмый туган авылы колхозында эшләгән; буш вакытларын кул эшләре артында vткәрергә яраткан. Ул матур итеп торле әйберләр теккән, сарык йонын эрләгән, матур-матур киемнәр бәйләгән. Кызларына оекбашлар, перчаткалар, кофталар һәм кvлмәкләргә кадәр бәйләп киендергән. Ул вакытлар матур киемнәрне сатып алырга бик кыен иде, шуна әлеге әйберләр белән киенгән кызлар чын-чынлап сокланырлык булган. Кызларына гына тvгел, сорап китгән авылдашларына бәйләп бирә торган булган оста куллы Зәкия, ул еш кына бvләккә дип тә торле-торле киемнәр бәйләп биргән.

Сәидә Хәсән кызы матур һәм хәерле гомер кичергән: олы картлыгына кадәр бәйләv эшен ташламаган. Кызларын да балачактан ук шул ук һонәргә ойрәтеп калдырган. Олы кызы Зәкия балачактан ук доктор булырга хыялланган, әмма хыяллар һәрвакыт тормышка ашмый – тегvче һонәрен vзләштерергә туры килә. Профессияле булган кыз, яшьтәшләре кебек туган якларыннан чит якларга бәхет, кәсеб эзләргә дип Мәскәvгә юллана һәм Мәскәv тегv фабрикасында хезмәт биографиясен башлап жибәрә. Аннары «Слава» сәгать заводында хезмәт итеп ала. Унбиш елдан артык «Седексо» дигән ябык корпоратив ашау ресторанында эшли. Шул гомер эчендә Зәкия башкалабыз Мәскәvдә гаилә кора һәм Ильмира кызы белән Марат улын тәрбияләп vстерә.

Бар жирдә дә тырыш, булдыклы, кешеләр белән уртак тел таба белvче Зәкия Мәхмvт кызын туган якларына каны тарта: ул Татар Юнкиенә кайта һәм ун еллап биредә яши инде. Ул бик тә яратып бакчасында чәчәкләр, яшелчәләр vстерергә тотына. Әмма балачактан тик торырга ойрәнмәгән хатын-кыз, лаеклы ялга чыккач та әнисе ойрәткән һонәрне онытмый. Барысын янадан исенә тошереп, сарык йонын эрләргә ойрәнә. Кызы Ильмира белән улы Марат Зәкия әниләренен туган коненә электр йон эрләгеч бvләк итәләр. Шулай итеп эш кайный башлый. Ана яшь - комачаулык тvгел. Комеш яшьтәге Зәкия Мәхмvт кызы Утешева актив эшчәнлеген жәеп жибәрә: СВО солдатларына сарык йоныннан жылы оекбашлар бәйләп бирә.

- Туган якта яшәп Туган ил очен хезмәт итә Зәкия апа Утешевабыз. Үткән ел коз коне ул 20 пар йорәк жылысын кушып сарык йоныннан бәйләп биргән носкиларны СВОда хезмәт иткән хәрбиләргә, укучыларыбыз язган открыткалары-хатлары, vргән маскировка

челтәрләре белән бергә жибәргән идек. Зәкия апабыз йон носкиларны бәйли дә мәктәпкә китереп бирә, ә без аны махсус хәрби операциядә катнашучыларга жибәрергә дип районга тапшырабыз. Быел кыш буе тагы 22 пар носкины госпитальдә яткан солдатларга жибәрv очен мәктәбебезгә алып килде; укучыларыбыз тагын хатларын язды, маскировка челтәрләрен vрде, - дип сойләде якташы Зәкия апа, укучылары турында РМ гомуми белем бирv мактаулы хезмәткәре, Мордовиянен атказанган укытучысы Торбеево районы Татар-Юнки авылындагы Жуково урта гомуми белем бирv мәктәбенен структур бvлекчәсе директоры, авыл жирлеге депутаты Тәнзилә Әхмәт кызы Агишева. - Зәкия Мәхмvт кызы Утешевага бар эшендә Мәскәvдән жәй коннәре туган якларына кайткан Равилә сенеле ярдәм итә. Аларга бик зур рәхмәт, гаиләләренә иминлек, нык сәламәтлек телибез.
Бvгенге авыр коннәрдә, туган жирләреннән, гаиләләреннән, әти-әниләреннән аерылып, куркыныч янаган жирләрдәге егетләребезгә без изге теләкләребез һәм эш-гамәлләребез белән генә ярдәм итә алабыз. Чын кvнелдән аларнын иминлектә әйләнеп кайтуларын телибез.

**Наилә НАСЫРОВА**